СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР АТЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы. 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**19 октябрь 2020 ел** **№ 2**

**Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл жирлеге Кушлавыч авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл жирлеге Кушлавыч авылында Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 63 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елнын 10 ноябренә 13 сәгать 30 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл жирлеге Кушлавыч авылында Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 63 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 10 ноябренә 14 сәгать 30 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: 8 Март урамында яшәүчеләр

2нче этап: Тукай урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл жирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- 8 Март урамында суүткәргеч челтәр коесы өчен люк капкачы сатып алу-1 данә;

-Тукай-8 Март урамнары киселешендә Кызыл елгасы аша җәяүлеләр күпере ясау өчен материаллар сатып алу;

- юл-урам челтәрен тигезләү өчен вак таш сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл жирлеге башкарма комитетына акчаны жыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен жибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл жирлеге Кушлавыч авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык жыенын оештыручы итеп Утар - Аты авыл жирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп жыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 63 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар - Аты авыл жирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева